**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Сәвәләй торак пунктында гражданнар җыены карары**

**21.11.2024** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең Сәвәләй торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар һәм ялгыз өлкәннәр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең Сәвәләй авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2025 елда үзара салымны 600 (алты йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Сәвәләй авылына кергән юл кыраендагы агачларны кыркып алу).
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ленин урамы һәм Яшьләр урамы буйлап юлларны төзәтү).
- урамнарны яктырту җайланмасы (урамнарны яктыртучы лампаларны төзекләндерү).
- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын сүндерү кудыкларын сатып алу һәм урнаштыру).

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Сәвәләй авыл җирлеге башлыгы** **С.К. Маклаков**